…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 5 2015. Февраль
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА:
## 70 ЧАКРЫМ АРА КҮП ТҮГЕЛ




Мәктәбебезнең 9 нчы сыйныф укучылары Советлар Союзы Герое Бари Габдрахмановның туган авылы Кармышка барып, андагы авыл музеенда каһарман якташыбызның язмышы, батырлыклары хакында ишетеп-тыңлап кайттылар. Тагын шунысы кызык, яшь сәяхәтчеләр авыллар арасын чаңгылар белән узган. Олуг юбилей уңаеннан оештырылган шундый озын сәфәргә Рафик Гатин җитәкчелегендә 9 нчы сыйныф егет-кызлары, барлыгы 16 укучы чыга. Карлы кыр юлларыннан уза-уза, алар әүвәл Кармышка туктала, ә кайтуышлый Югары һәм Түбән Кәминкә авылларына, Керкәлегә кереп, яу кырларында ятып калганнар истәлегенә куелган һәйкәлләргә чәчәкләр салганнар. Иртән юлга чыгып, 70 километрлап ара үткән укучылар Лашманга кичке дүртләргә кире әйләнеп кайтканнар. Әлеге акцияне уздырышырга балаларга "Бердәм Россия" партиясе дә ярдәм иткән. Менә нинди чыдам, булган егетләр безнең 9 нчы сыйныфта. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: "Ягез әле, егетләр!" бәйгесендә бу сыйныф ике 10 нчы сыйныф командаларын узып, лаеклы рәвештә 2 нче урынга чыкты.





Әлеге сәяхәттән күренешләр.

*БУ АЙДА…хәрби-патриотик айлык кысаларында бик чаралар уздырылды. Ветеран укытучы Ахтәм абый Фатыйхов призына "Күңелле стартлар" ярышында 8 нче сыйныф командасы иң җитезләре дип табылды. Афәрин, сигезләр!*

*БУ АЙДА… 18 нче февральдә мәктәбебездән "Дуслык" командасы районда Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган брейн-ринг уенында катнашты. Бу көнне температура бик түбән булу сәбәпле, кайбер команда әгъзалары килә алмады. Ләкин безнекеләр 6 кеше урынына 4 кеше катнашып, лаеклы рәвештә икенче урынны алды.*

*БУ АЙДА… 11 нче сыйныф укучылары математика һәм рус теленнән сынау шартында имтихан тапшырдылар. Нәтиҗәләр уртача…*

*БУ АЙДА… 7 нче февральдә казан шәһәрендә үткән И. Хәлфин исемендәге Республикакүләм фәнни-эзләнү конференциясе булып узды. Анда Газимзянова Рания беренче урынны алды.*

*БУ АЙДА…9 нчы сыйныф укучысы Шәйхетдинов Илшат татар теленнән, 10 нчы сыйныф укучысы Гатина Гөлназ һәм 11 нче сыйныф укучысы Галимова Алсинә әдәбияттан Республика олимпиадасында чыгыш ясадылар.*

# МИНЕМ БУШ ВАКЫТЫМ –МИНЕМ СӘЛАМӘТЛЕГЕМ.

***15 НЧЕ ФЕВРАЛЬДӘ БЕЗНЕҢ МӘКТӘПТӘ ЛАШМАН АВЫЛЫ КУБОГЫНА ЙӨЗҮ ЯРЫШЛАРЫ БУЛЫП УЗДЫ. БЕЗ -- ИКЕНЧЕ!!!***

Бу ярышларга дүрт районнан йөзүчеләр катнашты: Мөслим, Алексеевск, Яңа Чишмә, Чирмешән командалары үзара көч сынашты. Барлык катнашучылар килгәч, ярышны ачу тантанасы булды. Тантанада гимнны яңгыраткач, баш судья Билялов Фаиз абый ярышның максаты, узу тәртибе белән таныштырды. Һәркем тырышты. Ярышның оештыру моментында бигрәк тә безнең Лашман мәктәбенең өлкән сыйныфларында укучы кызлар зур ярдәм күрсәттеләр. Әлеге бәйгедә район данын яклаучылар – гадәттәгечә, Лашман мәктәбе һәм Чирмешән лицее укучылары. Читтән килгән көндәшләр көчле, бигрәк тә мөслимлеләр -“каты чикләвек” икән. Карап торсаң, араларында телевизорда күрсәтелүче зур ярышлардагы саллы спортчылардай, балык кебек, бик “ансат” йөзүчеләре бар. Ныклы күнегүләр үткәрмәсәң, алар белән җиңел генә алышам димә дә. Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Лашман мәктәбендә үткән ярышларда күп дистанцияләрдә Мөслим йөзүчеләре өстен булып чыкты. Яңа Чишмә районы егетләре дә, күз тимәсен - осталар. Ә безнекеләрдән, 50 метрга баттерфляй ысулы белән йөзүдә кызлар арасында Елена Ерошкина, яшүсмерләрдән Равил Миһманов - өченче урын ияләре. Брасста (50 метрга) Аидина Ихсанова - икенче, 100 метрга брасста Айнур Сәмигуллов һәм Инсаф Дәүләтшиннар призлы урында. Ришат Гайсинның 50 метрлы дистанциядә - (ирекле стильдә) өченче күрсәткеч. 50 метрга чалкан ятып йөзгән Илшат Шәйхетдинов финишка беренче килде. Аидина Ихсанова 100 метрга брасста да өченче призлы урын алды. Айнур Сәмигуллов брасста 50 метрны иң тиз узучы булып танылды. Бу төрдә Равил Миһманов - икенче. 100 метрга чалкан ятып йөзеп, Ләйлә Нуретдинова - икенче, Гадел Ибәтуллин өченче урын ияләре булдылар. 100 метрга ирекле стильдә дә йөзеп, Елена Ерошкина, Ләйлә Зөфәрова, Ришат Гайсин, Айрат Шәйхетдинов призлы урын ияләре буларак, медаль һәм Дипломнар белән бүләкләнделәр. Ә төп Кубокны Лашман авыл җирлеге башлыгы Рәфхать Фәттахов ярышның җиңүчеләренә - мөслимлеләргә тапшырды.



**Ну, егетләр, сынатмагыз!!!**

АФӘРИН




**Менә безнең команда!!!**

## “Ягез әле, ЕГЕТЛӘР!” “Ягез әле, ЕГЕТЛӘР!” “Ягез әле, ЕГЕТЛӘР!”



**Хөрмәтле егетләр! Барыгызны да бәйрәм белән котлыйбыз! Сезгә уңышлар, нык исәнлек телибез.**




23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне. Тагы әле бу көнне без әтиләребезне, абыйларыбызны, энеләребезне, гомумән барлык ир-егетләрне бәйрәм белән котлыйбыз. Армия хезмәтендә булганмы ул, юкмы – барысы да алар Ватан сакчылары. Әлеге бәйрәм уңаеннан ел саен мәктәбебездә “Ягез әле, егетләр!” бәйгесе уздырыла. Ел саен һәр сыйныфтан егетләр командасы зирәклектә, көчтә, белемлелектә, хәйләкәрлектә, үткерлектә көч сынашты. Илназ абый аларга нинди генә бәйгеләр әзерләмәгән иде. Идәннән этелеп күтәрелүдә 11 нче сыйныфтан Миникеев Фаил беренчелекне бирмәсә, кул көрәштерүдә 9 нчы сыйныфтан Гайфетдинов Данияр алга чыкты. Ә менә Мухуббуллин Искәндәр (9 нчы сыйныф командасыннан) иң үткен күзлесе икән: мишеньнәрне көнбагыш чирткән кебек кенә юк итте. Иң “тәмле” конкурс – лимон ашауда җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә булмады. Барысы да бирелгән лимонны йөзләрен чытмыйча, мактап-мактап, елмаеп ашадылар. Әллә грипп эпидемиясеннән файда күрмәкчеләр, язгы авитаминоз.... Белмәссең!. Беренчелекне 11 ләр бирмәде, икенче урында 9 нчылар, өченче һәм дүртенче урыннарны 10нар бүлеште. Молодцы, егетләр!

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**